**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2312**
**19.05.2020**

Башкарма комитетның аерым карарлары
үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезләмә хакында» 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 һәм 5.22 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның аерым карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Муниципаль мөлкәт өчен аренда түләвенең базар бәясен билгеләү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 5261 номерлы;

2) «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Муниципаль мөлкәт өчен аренда түләвенең базар бәясен билгеләү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 5261 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 5 апрелендәге 1248 номерлы;

3) «Муниципаль мөлкәт өчен аренда түләвенең базар бәясен раслау турында» 2008 елның 31 декабрендәге 4235 номерлы;

4) «Башкарма комитет Җитәкчесенең «Муниципаль мөлкәт өчен аренда түләвенең базар бәясен раслау турында» 2008 елның 31 декабрендәге 4235 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 26 гыйнварындагы 280 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов